# *Туган телем – әткәм-әнкәмнең теле*

**Хөрмәтле әти-әниләр!**

Туган телне саклау һәм үстерү - көнүзәк мәсьәлә, чөнки телнең яшәеше, үсеше халыкның аны көндәлек тормышта ни дәрәҗәдә куллануына бәйле!

Туган тел- бала тугач та үзләштерелә башлаган олы хәзинә.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!

Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Татар халкының мәшһүр шагыйре, бөек әдип **Габдулла Тукай** үзенең туган телгә булган ихтирамын әнә шулай матур итеп әйтеп биргән. Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул **әти-әни**, **туган җир, Ватан** сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә бөек, изге сүз.

Туган телгә баланы аның иң газиз кешесе- әнисе өйрәтә, шул телдә аңа назлы бишек җырлары җырлый, иркәли, юата. Шуңа күрә аны халык **ана теле** дип атый. Баланың ана телен үзләштерүе һәм аны актив куллануы, шул телдә тәрбия һәм белем алуы һәрьяклы үсеше өчен уңай шарт булып тора.

Балалар бакчасында сезнең балалар белән атнага 3 тапкыр ана теле эшчәнлеге үткәрелә. Эшчәнлекләрне югары категорияле балаларны татар теленә өйрәтүче тәрбияче ________________________________________ алып бара.

Тел ананың балага биргән иң зур бүләге, баланың туган көненнән туплап килгән хәзинәсе. Балаларыбызны шушы бүләктән мәхрүм итмик!

## Балалар белән өйдә өйрәнергә тәкъдим итеЛә!

**Салкын су, чиста су,**
**Баламның битләрен ю,**
**Баламның күзләрен ю.**
**Күзләре ялкынлансын,**
**Үзе нык, таза булсын!**

**Бу бармак-бабай,**
**Бу бармак-әби,**
**Бу бармак-әти,**
**Бу бармак-әни**
**Бу бармак – нәни бәби,**
**Аның исеме Чәнти.**

## Туп

**Әминә елый үкереп,**

**-Тубым суга төште,- дип.**

**-Чү, Әминә, елама:**

**Туп батмый ул елгада.**

Әминә Бикчәнтәева.



## Мияу!

**Песи, песи, пескәем,**

**Соры синең төскәең.**

**Йомшак синең йоннарың,**

**җылы синең туннарың.**

Роберт Миңнуллин.



## Минем кызым-курчагым

**Әй акыллы курчагым,**

**Йом күзеңне, бәлли-бәү.**

**Башка бер сүз дә дәшмим,**

**Йоклап алыйк без икәү.**

Җәвад Тәрҗеманов.





## “Чәбәк” уены

**Чәп-чәп чәбәкәй**

**Безнең куллар бәләкәй!**

**Ә хәзер тизрәк-тизрәк**

**Чәбәклик күңеллерәк!**



**Туп, туп, матур туп,**

**Сикер, сикер, матур туп.**

**Туп, туп, матур туп,**

**Сикер, сикер, матур туп.**



**Әй куян, куян,**

**Кечкенә генә,**

**Бик йомшак кына,**

**Бик куркак кына.**

**Ике колагы**

**Озынкай гына,**

**Аягы җиңел-**

**Мамыктай гына.**

# ***Жырлы-биюле уен “Карусель”.***



***Әллә-лә, әллә-лә,***

***Карусель  әйләнә,***

***Матур курчак әйләнә,***

***Зур-зур аю әйләнә,***

***Кечкенә куян әйләнә.***



***Әллә-лә, әллә-лә,***

***Карусель әйләнә,***

***Матур курчак әйләнә,***

***Зур-зур аю әйләнә,***

***Кечкенә куян әйләнә.***



